СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.06.2020 № 48/4

На № ________ от ____________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чаралары турында**

«Тукай муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чаралары турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Район Башкарма комитетына:

- милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгыту мәсьәләләре буенча милли диаспоралар вәкилләре белән эшне дәвам итәргә;

- «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасы чараларының үтәлешен тәэмин итәргә;

- «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын расларга;

3. Авыл җирлекләре Башлыкларына тәкъдим итәргә:

- авыл җирлегендә милли-мәдәни чараларны тормышка ашыруда актив катнашырга;

- авыл җирлекләре территориясенә чит ил гражданнарының килүен системалы рәвештә анализларга;

- авыл җирлеге территориясендә урнашкан объектларның террорчылыкка каршы сакланышына карата таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә, ирекле халык дружинасы әгъзалары белән берлектә, теркәлмәгән затларның законсыз яшәү мөмкинлеген ачыклау максатыннан, буш йортларны даими йөреп чыгуны оештырырга.

4. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә район халкына рухи-әхлакый тәрбия бирүгә, милләтара һәм конфессияара мәсьәләләрне даими яктыртуга юнәлдерелгән материалларны бастырып чыгаруны дәвам итәргә.

5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары                                        Р.И. Закиров